ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07» май 2025 ел № 420

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәгариф идарәсе” муниципаль учреждениесе һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәдәният идарәсе” муниципаль учреждениесе үзәкләштерелгән бухгалтериясен техник тәэмин итүне һәм хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында**

Арча муниципаль районы Башкарма комитетының социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм үзәкләштерелгән бухгалтерияләр хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүне камилләштерү максатларында КАРАР БИРӘ:

1. Расларга:

1) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәгариф идарәсе” муниципаль учреждениесе һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәдәният идарәсе” муниципаль учреждениесе үзәкләштерелгән бухгалтериясе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында Нигезләмәне 1нче Кушымта нигезендә.

2) Үзәкләштерелгән бухгалтерияне техник тәэмин итүне һәм аңа хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү турында Нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә.

1. Арча муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

- “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәгариф идарәсе” муниципаль учреждениесе һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәдәният идарәсе” муниципаль учреждениесе үзәкләштерелгән бухгалтериясе хезмәткәрләренең, техник тәэмин итүне һәм хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы үзәкләштерелгән бухгалтерияләр хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында” 2024 елның 27 июнендәге 443 номерлы карары;

- “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәгариф идарәсе” муниципаль учреждениесенең һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының “Мәдәният идарәсе” муниципаль учреждениесенең үзәкләштерелгән бухгалтерия хезмәткәрләренең, үзәкләштерелгән бухгалтерияне техник тәэмин итүне һәм хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында” Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 27 июнендәге 443 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында” 2024 елның 2024 елның 2 нояборендәге 812 номерлы карары.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга:.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче А.Г.Хисаметдинов

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының
07.05.2025г ел, № 420
Карарына
1нче Кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәгариф идарәсе” муниципаль учреждениесе һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәдәният идарәсе” муниципаль учреждениесе үзәкләштерелгән бухгалтериясен техник тәэмин итүне һәм хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында Нигезләмә**

Әлеге Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәгариф идарәсе” муниципаль учреждениесе һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәдәният идарәсе” муниципаль учреждениесе үзәкләштерелгән бухгалтериясен техник тәэмин итүне һәм хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәгариф идарәсе” муниципаль учреждениесе һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәдәният идарәсе” муниципаль учреждениесе эшчәнлеген оештыруның аерым мәсьәләләрен регламентлаштыра һәм үзәкләштерелгән бухгалтерияләр хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләмнәрен һәм аларны бирү шартларын билгели.

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәгариф идарәсе” муниципаль учреждениесе һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәдәният идарәсе” муниципаль учреждениесе үзәкләштерелгән бухгалтерияләре хезмәткәрләренең хезмәт хакы вазыйфаи окладтан, тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәдән, эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәдән, акчалата бүләкләүдән, матди ярдәмнән һәм еллык түләүле отпуск биргәндә бер мәртәбә түләүдән, эш нәтиҗәләре буенча премияләрдән тора.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәгариф идарәсе” муниципаль учреждениесе һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәдәният идарәсе” муниципаль учреждениесе үзәкләштерелгән бухгалтерияләре хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфа исеме | Вазыйфаи оклад, сум |
|---|---|
| Баш хисапчы | 34 600 |

| | |
|---|---|
| Бүлек башлыгы | 30 500 |
| Әйдәп баручы икътисадчы | 27 800 |
| Әйдәп баручы хисапчы | 27 800 |
| Хисапчы | 26 400 |

Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлекләренең штат саны кимендә 5 берәмлек булырга тиеш.

3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәгариф идарәсе” муниципаль учреждениесе һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәдәният идарәсе” муниципаль учреждениесе Үзәкләштерелгән бухгалтерияләре хезмәткәрләренә билгеләнә:

1) тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка ай саен түбәндәге күләмнәрдә өстәмә:

| Эш стажы булганда | Айлык өстәмә, процентларда |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 7 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан артык | 15 |

2) эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка ай саен вазыйфаи окладның 45 процентыннан артмаган күләмдә өстәмә түләү;

3) вазыйфаи окладның 2 проценты күләмендә ай саен акчалата бүләкләү;

4) еллык түләүле ял биргәндә вазыйфаи окладның елына 120 проценты күләмендә бер мәртәбә түләү.

Әгәр хезмәткәргә календарь ел дәвамында еллык түләүле ял бирелмәсә, бер мәртәбә бирелә торган түләү аңа декабрьдә эшләгән вакытка пропорциональ рәвештә, эштән киткән очракта – соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча түләнә.

Эшнең беренче елында еллык түләүле ял бирелгәндә хезмәткәргә бер мәртәбә түләү календарь елында эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт эшкә кергән көннән агымдагы календарь елның 31 декабренә кадәр исәпләнә.

5) билгеләнгән хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә акчалата бүләкләү, матди ярдәм;

6) эш нәтиҗәләре буенча премия.

4. Вазыйфаи окладлар, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләме арттыру ягына тулы бер сумга кадәр түгәрәкләнергә тиеш.

5. Эш нәтиҗәләре буенча премия түбәндәге шартларны исәпкә алып түләнә:

1) премияләр Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәгариф идарәсе” муниципаль учреждениесе һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәдәният идарәсе” муниципаль учреждениесе Үзәкләштерелгән бухгалтерияләренең вазыйфаи инструкцияләрдә һәм хезмәт шартнамәләрендә каралган бурычларны вакытында һәм сыйфатлы үтәгән өчен, җитәкчелек заданиеләрен, боерыкларын һәм күрсәтмәләрен вакытында һәм сыйфатлы үтәгән өчен премияләр түләү турында Карар кабул ителгән көнгә хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы хезмәткәрләренә түләнә;

1) башка эшкә күчерелү, уку йортларына керү, яңадан әзерләү (квалификациясен үзгәртү) һәм квалификациясен күтәрү курсларын узу, санын яисә штатын кыскарту буенча эштән азат ителү, пенсиягә чыгу, йөклелек һәм бала табу буенча ял бирү, өч яшькә кадәр бала карау һәм башка нигезле сәбәпләр буенча буенча исәп-хисап вакыты буларак кабул ителгән тулы булмаган вакыт эшләгән үзәкләштерелгән бухгалтерияләр хезмәткәрләренә премияләр түләү әлеге исәп-хисап чорында эшләп бетерелгән вакыт өчен башкарыла.

2) премияләр исәпләү өчен исәп-хисап вакыты буларак кабул ителгән чор эчендә эшкә кергән үзәкләштерелгән бухгалтерияләр хезмәткәрләренә аның хезмәт керткән өлешен һәм фактта эшләнгән вакытын исәпкә алып премия түләнергә мөмкин;

5) үзәкләштерелгән бухгалтерияләр хезмәткәрләренә премияләр календарь ел дәвамында хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә исәпләнә;

6) премияләр исәпләү өчен исәп-хисап чоры сыйфатында биремнәрне үтәү өчен билгеләнгән айга, кварталга, яртыеллыкка, елга яисә башка вакытка тигез булган вакыт кабул ителә;

7) премияләр суммалары максималь күләмнәр белән генә чикләнми;

8) җитештерүдә кимчелекләр җибәргән һәм хезмәт дисциплинасын бозган үзәкләштерелгән бухгалтерияләр хезмәткәрләре премиядән тулысынча яисә өлешчә мәхрүм ителәләр.

Премиядән тулысынча яки өлешчә мәхрүм итү җитештерү кимчелеге һәм хезмәт дисциплинасын бозу булган премияләрне исәпләү өчен исәп-хисап чоры өчен башкарыла.

Премия бирү яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча башкарыла һәм премия бирүнең нигезләре һәм күләмнәре күрсәтелгән хокукый акт белән рәсмиләштерелә.

6. Матди ярдәм түләү хезмәткә түләү фондын экономияләү исәбенә башкарыла, түләү өчен нигез булып яллаучы (эш бирүче) вәкиле җитәкчесенең хокукый акты тора.

7. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәгариф идарәсе” муниципаль учреждениесе һәм Татарстан

Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәдәният идарәсе” муниципаль учреждениесе Үзәкләштерелгән бухгалтерияләре хезмәткәрләренең еллык хезмәт хакы фонды түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT = \sum_{1}^{n}((O_d + 0{,}3 * O_d) * k) * (1 + t) + \sum_{1}^{n} P * (1 + t)$$

Анда:

$FOT$ - җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең еллык хезмәт хакы фонды;

$O_d$- җитәкчегә һәм белгечкә айга вазыйфаи окладлар түләүгә акчалар суммасы;

$0{,}3 * O_d$ – тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләүгә, эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләүгә, акчалата бүләкләүгә, еллык түләүле ял, матди ярдәм күрсәткәндә бер мәртәбә түләүгә акчалар суммасы;

Р – җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең еллык премия фонды *(әлеге Нигезләмәнең 3 пунктындагы 5 пунктчасында билгеләнгән шартлардан чыгып билгеләнә)*

$n$ - җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең штат саны;

$k$ – 12 ай;

$t$ - хезмәткә түләү буенча түләүләргә исәпләүләр.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының
07.05.2025 ел, № 420
Карарына
2нче Кушымта

**Үзәкләштерелгән бухгалтериянең техник тәэмин итүне һәм хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында**
**Нигезләмә**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәгариф идарәсе” муниципаль учреждениесенең һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәдәният идарәсе” муниципаль учреждениесенең үзәкләштерелгән бухгалтериясен техник тәэмин итүне һәм хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү разрядына бәйле рәвештә тариф коэффициентына тапкырланган тариф ставкасы (оклад) билгеләнә.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәгариф идарәсе” муниципаль учреждениесенең һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәдәният идарәсе” муниципаль учреждениесенең үзәкләштерелгән бухгалтериясен техник тәэмин итүне һәм хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү разрядлары диапазоны түбәндәге чикләрдә билгеләнә:

| Һөнәр исеме | Хезмәт өчен түләү разряды |
|---|---|
| Гардеробчы, ишегалды себерүче, курьер | 1 |
| Каравылчы (вахтер), җитештерү һәм хезмәт биналарын җыештыручы, лифтерчы, кладовойчы, йөк төяүче | 1 – 2 |
| Электрон-исәпләү һәм исәпләү машиналары операторы, биналарга комплекслы хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау эшчесе | 2 – 4 |
| Күчерү һәм тапкырлау машиналары операторы | 2 – 3 |
| Җиңел автомобиль йөртүчесе | 4 – 5 |

Искәрмә:

Җитештерү һәм хезмәт биналарын җыештыручыларга икенче разрядлы тариф ставкасы җитештерү биналарын, шул исәптән җитештерү калдыкларын, санузелларны һәм җәмәгать бәдрәфләрен җыештыру эшләрен башкарганда билгеләнә.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәгариф идарәсе” муниципаль учреждениесенең һәм Татарстан Республикасы

Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәдәният идарәсе” муниципаль учреждениесенең үзәкләштерелгән бухгалтериясен техник тәэмин итүне һәм аңа хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы эшчеләргә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары) түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Бердәм тариф челтәренә түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (окладлары), сум |
|---|---|---|
| 1 | 1,0000 | 23 320,0 |
| 2 | 1,0114 | 23 586,0 |
| 3 | 1,0233 | 23 863,0 |
| 4 | 1,0346 | 24 127,0 |
| 5 | 1,0473 | 24 423,0 |

Тариф ставкасыннан (окладтан) тыш түбәндәге түләүләр билгеләнә:

1) эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен айлык тариф ставкасына айлык тариф ставкасының 5 процентыннан артмаган күләмнәрдә айлык өстәмә.

2) премияләр хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы хезмәткәрләргә премияләр түләү турында карар кабул ителгән көнгә вазыйфаи инструкцияләрдә һәм хезмәт шартнамәләрендә каралган бурычларны вакытында һәм сыйфатлы үтәгән, җитәкчелек биремнәрен, боерыкларын һәм күрсәтмәләрен вакытында һәм сыйфатлы үтәгән өчен түләнә;

3) еллык түләүле ял биргәндә вазыйфаи окладның елына 100 проценты күләмендә матди ярдәм.

Әгәр хезмәткәргә календарь ел дәвамында еллык түләүле ял бирелмәсәматди ярдәм аңа декабрьдә эшләгән вакытка пропорциональ рәвештә, эштән киткән очракта – соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча түләнә.

Эшнең беренче елында еллык түләүле ял бирелгәндә хезмәткәргә матди ярдәм календарь елында эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт эшкә кергән көннән агымдагы календарь елның 31 декабренә кадәр исәпләнә.

3) билгеләнгән хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә матди ярдәм.

Хезмәткәрләргә тиешле федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларда каралган бүтән түләүләрне башкарырга.

Айлык һәм башка түләүләр күләмен арттыру ягына тулы бер сумга кадәр түгәрәкләргә кирәклеген билгеләргә.